**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«05» 08 2024 ел Яр Чаллы №82

Түбән Суыксу авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, район Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

## КАРАР БИРӘМ

1. Түбән Суыксу авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга (tukay.tatarstan.ru).
3. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.
4. Билгеләргә:
4.1. үткәрү вакытын:
4.1.1. 2024 елның 21 августында 13:30 сәгатьтә, үткәрү урынын: Түбән Суыксу авылы, Үзәк ур., 1А, мәдәният йорты;
4.1.2. 2024 елның 21 августында 14:00 сәгатьтә, үткәрү урынын: Мазино авылы, Үзәк ур., 18нче йорт янында;
4.1.3. 2024 елның 21 августында 14:30 сәгатьтә, үткәрү урынын: Куады авылы, Үзәк ур., 11В, мәдәният йорты;
4.1.4. 2024 елның 21 августында 15:00 сәгатьтә, үткәрү урынын: Югары Суыксу авылы, Үзәк ур., 32Б, мәдәният йорты;
4.1.5. 2024 елның 21 августында 15:30 сәгатьтә, үткәрү урынын: Яңа Мусабай авылы, Үзәк ур., 2Б, фельдшер-акушерлык пункты;
4.2. материаллар белән танышу вакытын: дүшәмбе – җомга 9:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр (төшке аш 12:00 сәгатьтән 13:00 сәгатькә кадәр);
4.3. проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү өчен адрес: Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил пр., 46, 203 каб.;
4.4. тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2024 елның 7 августыннан 2024 елның 21 августына кадәр кабул ителә.

5. Материаллар экспозициясе Түбән Суыксу авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында 2024 елның 14 августыннан 2024 елның 21 августына кадәр оештырылачак.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2024 елның 05.08 82 номерлы карарына кушымта

# ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

Әлеге тәртип Түбән Суыксу авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына район халкы тарафыннан язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Проект районның рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.

4. Халык тыңлаулары секретаре фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.

5. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә.

6. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә: чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә; проект буенча фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр; фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.

7. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла.

8. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә: халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме; халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны; халык тыңлауларында катнашкан авыл җирлеге гражданнарының саны; халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

9. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм мәҗбүри рәвештә «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырылырга һәм районның рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.